Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР №XL-13**

Балык Бистәсе штп. 2023 елның 28 июле

«Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге муниципаль милкендәге кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арендалый торган күчемсез мөлкәтне читләштерү турында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2020 елның 6 октябрендәге II-5 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 29 декабрендәге 605-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасының «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына ярашлы рәвештә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

«Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге муниципаль милкендәге кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арендалый торган күчемсез мөлкәтне читләштерү турында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2020 елның 6 октябрендәге II-5 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.1 Мондый мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны тормышка ашырганда кече һәм урта эшкуарлык субъектлары сатып ала торган муниципаль милектәге арендалана торган мөлкәткә түләү бер тапкыр яки ваклап түләү шартында тигез өлешләрдә айлык яисә квартал саен түләүләр юлы белән гамәлгә ашырыла. Сатып алуга өстенлекле хокукны тормышка ашырганда мондый мөлкәт өчен түләүне кичектерү срогы тиндәшле Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый акты, Россия Федерациясе субъекты законы, муниципаль хокукый акт белән билгеләнә, ләкин күчемсез мөлкәт өчен биш елдан да ким һәм күчемле мөлкәт өчен өч елдан да ким булырга тиеш түгел.»;

4.3 пунктта «түләүле читләштерү» сүзләреннән соң «күчмә һәм» сүзләрен өстәргә;

2.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2 Муниципаль унитар предприятие, федераль законның 22.07.2008 №159-ФЗ номерлы 3 маддәсендә күрсәтелгән мөлкәтне сатып алуга арендаторның

өстенлекле хокукын гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган таләпләргә җавап бирә торган, хуҗалык алып бару яисә оператив идарә итү хокукындагы һәм арендалана торган зат тарафыннан күчемле һәм күчемсез мөлкәтне түләүле читләштерүне гамәлгә ашырырга хокуклы.»;

1.2.2 пунктында «күчемле» сүзен «күчемле һәм күчемсез» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы Р.Р. Ислямов